**«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»**

**ПАЛАТА ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**

**ЖИР һӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ**

---

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**«__23__»____04_______2019___ел** **№_400_____**

“Муниципаль учреждениеләр, муниципаль казна предприятиеләре белән идарә итү хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләр белән хуҗалык эшчәнлеге алып бару хокукында муниципаль мөлкәтне рәсмиләштерү ( беркетү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”

2010 елның 27 июлендә кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210 нчы номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт властеның башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турындагы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”гы 880 нче номерлы Карарына үзгәрешләр кертү уңаеннан, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 13.06.2018 елгы “Административ регламентларны эшләү тәртибен һәм раслауны оптимальләштерү уңаеннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 676 нчы карары белән гражданнарның һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тормышка ашыруны, муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча структур подразделениеләрнең эшчәнлеген стандартлаштыру һәм регламентлаштыруны камилләштерүне тәэмин итү максатында.

1. Муниципаль учреждениеләр, муниципаль казна предприятиеләре белән идарә итү хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләр белән хуҗалык эшчәнлеге алып бару хокукында муниципаль мөлкәтне

рәсмиләштерү (беркетү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга (кушымта).

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр палатасының 2017 елның 23 июнендәге “Муниципаль учреждениеләр, муниципаль казна предприятиеләре белән идарә итү хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләр белән хуҗалык эшчәнлеге алып бару хокукында муниципаль мөлкәтне рәсмиләштерү (беркетү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 1294 нче номерлы Боерыгы белән расланган “Муниципаль учреждениеләр, муниципаль казна предприятиеләре белән идарә итү хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләр белән хуҗалык эшчәнлеге алып бару хокукында муниципаль мөлкәтне рәсмиләштерү (беркетү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты” үз көчен югалткан дип табарга.

3. Әлеге боерыкны үтәүгә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М.Ю. Исхакова